| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**5 августа 2016 г.** | Зеленодольск ш. | **КАРАР**<br>**№ 2071** |

Зеленодольск шәһәре, Гоголь ур., 27/8 адресы буенча җир кишәрлеген һәм анда урнашкан күчемсез милек объектларын алу турында

Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә 2013-2017 елларга Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 26.09.2013 ел, №2178 карары белән расланган «Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итү фонды турында» 21.07.2007 ел, №185-ФЗ Федераль закон нигезендә 2013-2017 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча муниципаль адреслы программаны тормышка ашыру максатларында һәм аларның статусы турында "Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

**КАРАР БИРӘ:**

1. Муниципаль ихтыяҗлар өчен Зеленодольск шәһәре, Гоголь урамы, 27/8 йорт адресы буенча урнашкан җир кишәрлеген һәм андагы авария хәлендәге һәм сүтелергә тиешле күпфатирлы торак йорт, шулай ук әлеге йортта кертелгән исемлек буенча урнашкан күчемсез милек объектларын (торак һәм торак булмаган бүлмәләр) алырга. (Кушымтада).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайты (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә һәм «Зеленодольская правда" газетасында урнаштырырга.
3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О. А. Матвеевага:

-чыгарыла торган күчемсез милекнең хокук ияләренә;

-күчемсез милеккә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы органга;

- МКУ "Торак сәясәте департаменты»на әлеге карарның күчермәсен җибәрергә.

4. МУ «Зеленодольск муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлеген урнаштыру схемасын раслауны тәэмин итәргә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче А. Х. Сәхибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2016 елның 5 нче августы, 2071
номерлы карарына кушымта

Гоголь ур., 27/8 нче күпфатирлы торак йортта урнашкан,
ашыгыч һәм сүтелергә тиешле дип танылган күчемсез милек объектын алу турындагы исемлек

| кв.с№ | Объектның кадастр (яки) шартлы номеры |
|---|---|
| 4 | 16:49:010110:541 |